# КАНАКО ВАТАНАБЕ – 200 МЕТРГА БРАСС БЕЛӘН ЙӨЗҮ БУЕНЧА ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНКАСЫ

07.08.2015, 18:46

СПОРТ

**Бу минутларда су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты кысаларында бу көннең өченче финал ярышлары тәмамланды. 200 метрга брасс белән йөзүдә дөньяның иң яхшы 8 спортчы кызы ярышты.**

Алтын медальне Япония кызы Канако Ватанаби алды, ул әлеге дистанцияне 2:21.15 секундта йөзеп узды. Финишка икенче булып америкалы Мика Лоуренс килде, аның күрсәткече - 2:22.44. Әмма иң кызыклы көрәш өченче урын өчен барды. Берьюлы өч спортчы кыз – Дания кызы Рикке Меллер Педерсен, Испания кызы Джессика Волл һәм Кытай кызы Ши Цзинлинь бортка бер үк вакытта кагылдылар (2:22.76) , бу исә бронза медаль берьюлы өч спортчыга да бирелә дигәнне аңлата.

ДЧ-2015. Йөзү

Хатын-кызлар. Брасс, 200 м.

1. Канако Ватанабе (Япония) - 2:21.15

2. Мика Лоуренс (АКШ) - 2:22.44

3. Джессика Волл (Испания) - 2:22.76

3. Рикке Меллер Педерсен (Дания) - 2:22.76

3. Ши Цзинлинь (Кытай) - 2:22.76

7 август. Казан. “Казан Арена”

Су спорт төрләре буенча 16 нчы дөнья чемпионаты Оештыру комитеты матбугат хезмәте

ЯҢАЛЫКЛАР ТАСМАСЫН АЧАРГА